Ислам һәм дин

# КЕШЕНЕҢ РУХИ ДӨНЬЯСЫ - ГАИЛӘДӘ....

**_Башкортостан республикасының ”Сәхибҗамал” исемен йөрткән татар хатын-кызлары һәм Уфа мөселман хатын-кызлары оешмалары инициативасы белән ”Мөнирә” мәчетендә гаиләнең рухи дөньясы проблемаларын эченә алган зур сөйләшү үтте._**



Милә Сәфиуллина

Бүгенге буын халкы һәм фән мондый да эсселекне һәм королокны хәтерләми. Ни эшлисең бит, килгән афәтне җиңү хәзергә кулдан килми. Шулай булгач, илгә килгән бәлә-казаларны күтәрергә, сабырлык белән эшләргә һәм яшәргә өйрәнергә кирәк. Сүзебезне шулай башлауның сәбәбе дә хатын-кызларыбызның бер нигә карамый искиткеч тырыш хезмәттә икәнлеген күреп шатлану, горурлык хисләре кичерү иде...

Әле күптән түгел Русия мөселманнарының үзәк диния нәзаратының Ислам университеты мөгаллимәләре оештыруында ”Лалә Тюльпан” мәчетендә зур әһәмияткә ия булган фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Темасы бик актуаль иде - ”Хәзерге җәмгыяттә мөселман хатын-кызларының әхлагы һәм рухи тормышы”. Конференциягә күп кенә дәрәҗәле дин белгечләре, галимнәр, яшьләр чакырылып килгән, чыгышларында күп проблемалар хакында сөйләшү барды, ә инде азагында бу фәһемле сөйләшүне арытабан дәвам итү турында тәкъдим кертелде. Уфа мөселман хатын-кызлары җәмгыяте җитәкчесе Мөнирә ханым Байгильдина сөйләшүне үзе төзеткән мәчеттә дәвам итәргә чакырды (Уфа шәһәренең Нижегородка бистәсе, ”Мөнирә” мәчете, 22-че автобус маршруты, ”Воронежская” тукталышы).

Һәм менә, Рамазан ае алдыннан ”Мөнирә” мәчете кунаклар кабул итте. Безнең уңганнарыбыз эссе дип тормаганнар, хәттә районнардан да килгәннәр иде, уфалыларны әйтеп торасы да юк. Алар арасында ”Сәхибҗамал” оешмасының агзалары аеруча күп иде. Яшь буынны тәрбияләү, аларның күңеленә миһербанлылык, дуслык, тугрылык, изгелек тойгылары салу мәсьәләсе игътибар үзәгендә булды. Мәсәлән, Башкортостан татар хатын-кызлары оешмасы җитәкчесе Гөлҗиһан Яһүдина хәзерге вакытта күп кенә хатын-кызларыбызның иҗтимагый тормышта армый-талмый катнашулары, хәттә үз эшләрен оештыруда күренекле эшкуарлар булып китүләре турында сөйләгәндә гаделлеккә, мал табуның хәләл юлларын үз итүгә чакырды. Шул исәптән, соңгы елларда һәм киләчәктә көтелгән табигый хәүефләр турында искә төшереп, галимнәр фараз иткәнчә, кешелек җәмгыяте куйган законнардан, шәригать кануннарыннан читләшмәскә чакырды. Һәм гаилә тәрбиясенең иң әһәмиятле икәнен ассызыклап әйтеп үтте.

”Сәхибҗамал” оешмасы агзасы Бәйнә Сәлимгәрәева ”тәрбиядә һәр нәрсә әһәмиятле” дип башлап китте үзенең чыгышын. ”Уфа мөселман хатын-кызлары оешмасы республикабызда киң билгеле иҗтимагый оешмага әверелеп бара”, - диде ул. Шәһәребездә эшләп килгән татар хатын-кызлары оешмасы ”Мөнирә” мәчете идарәсенең изге эшләрендә якыннан торып, зур ихласлык белән катнаша. Бүгенге хатын-кызның сафлыгы, аның җәмгыяттәге роле турында җыелышып сөйләшүгә дә алдынгы, укымышлы ханымнар килгәннәр. Чынлап та һәр җәмгыяттә дә, һәр чорда да тәрбия мәсьәләсе бөтен авырлыгы, бөтен җитдилеге белән хатын-кыз өстенә төшкән бит.

Мөселман халкына хас иң бөек кыйммәтләрнең берсе - ул гаилә булып яшәү. Ислам гаиләне мәхәббәт, мәрхәмәтлелек һәм бер-береңне аңлау чыганагы буларак карый. Ир-хатын мөнәсәбәте никахка нигезләнгән табигый бәйләнеш итеп күзаллана, гаилә тормышына динебездә зур урын бирелә. Бүген дә безнең әлеге оешмабызда җыелышып сөйләшү шушы хакта. Мине, мисал өчен, җәмгыятьтә гаиләгә тәүгә игътибар кимүе, ”гражданский брак” дигән, мөселманга хас булмаган, хатын-кызны кимсетү галәмәте үтә дә нык борчый. Никахлы гаиләләр арасында да аерылышулар еш очрый, әлбәттә, ләкин никахсыз яшәүдән бары ятим балалар, бәхетсез ялгыз хатыннар гына кала. Кызларыбызны үз кадерләрен белергә, яхшы ана булып, һәр яклап тәрбияле балалар үстерергә әзерләп җиткерә алмыйбызмы әллә? Нигә аларның байтагы үзен кимсетүгә юл куя икән? ”Гражданский брак” ирләрнең җавапсызлыгына юл куя. Кайберләре гомере буе хатын сайлый. Ә бит кешенең рухи дөньясы гаиләдә тәрбияләнә. Ата-ана икесе бер теләктә булып, үз уңай үрнәкләрендә тәрбияләсәләр генә, чын кеше үсә ала. Балалар яратылып, мәхәббәт эчендә, ихласлыкта үсәргә тиешләр. Шунда гына аларда уңай хисләр, кешеләрне ярату, ягымлы, кешелекле булу кебек матур сыйфатлар тәрбияләнә ала.

Әйе, хәзерге вакытта хатын-кыз аеруча төпкә җигелде: армый-талмый эшли, иҗат итә, дөнья көтә. Ә бит матди дөнья белән рухи дөнья бер медальнең ике ягы. Дөрес әйткәннәр бит борынгылар: ”Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән кермәс!” Изге ана сөте! Ана баланы дөньяга китерүче дә, газиз сөтен имезеп үстерүче, тәрбияләүче дә. Димәк, баланың рухи дөньясы иминлеге өчен дә без җаваплы!

Җәмгыяттә иминлек кешелекнең рухи дөньясы нинди булуга бәйле икәне һәр кемгә ачык. Бүген без яшәгән җәмгыять рухи яктан зәгыйфь булса - без гаепле. Һәряклап сәламәт, тәрбияле гаиләләр булсын дисәк, баланы кечкенәдән һәр эше, кылган гамәлләре өчен җаваплылык тотарга өйрәтик. Озак еллар дәвамендә булачак укытучыларны әзерләү мәшәкатьләре белән шөгыльләнүем миңа яшь кызлар белән дәвамлы аралашу мөмкинлеген бирде. Һәр группа биш ел буена синең белән аралаша. I курска килгәндә авыл тормышының барлык уңай яклары: эшчәнлек, тәрбиялелек, сафлык бөркелеп тора алардан.

Әйе, авылларда әле халык педагогикасы эшли. ”Кызның инәсе кырык, кырык беренчесе - чыбык” дигән мәкаль үз көчен югалтмаган. Кызларыбызны заман котырткычларыннан арчаларлык, иманга юнәлтерлек, аларның яшьлек сафлыгын сакларлык көч-куәтләр һәрбер авылда бар!



Кунаклар арасында Ислам дине буенча мәдрәсәләрдә һәм үзаллы белем алган укымышлы ханымнар күп иде. Шуларның берсе - эшкуар, дини китаплар сату кибетен оештырып, уңышлы эшләп килүче Асия Зиннур кызының чыгышын да бик кызыксынып тыңладылар. Ул дини китапларны чыгаручы нәшриятләрнең уңышлы эшләве, халыкның дини мәгълүмәтләргә ихтыяҗын канәгатьләндерү йөзеннән тематиканың киң булуы, галимнәрнең төпле хезмәтләре көннән-көн артуы турында сөйләде. Йөрәк кушуы буенча мәчеткә йөреп, беренче мәртәбә күренекле мөгаллимә Фатыйма Фаткуллинадан сабаклар алуы арытабан үз белемен арттыруга ярдәм итә бу киң карашлы, уңган ханыма.

Миякә районыннан килгән динле эшкуар ханымнар хәләл малның ырамлы, файдалы булуы, эшкә дәрт өстәве, җәмгыять файдасына эшләүләре куандырды. Чыгышларында яшь буынны хезмәттә тәрбияләүнең әһәмияте турында әйтеләр. Һәрбер чыгыш ясаучы, бу теманың үтә кирәклеген, актуаллеген ассызыклап, мондый җыелышларны даими рәвештә дәвам иттерергә кирәклеген әйтеп, киләсе очрашуны Авыргазы кунаклары үзләрендә үткәрергә тәкъдим итеп, чакырып, оештыручыларның ризалыгын алып киттеләр!

Тормыштагы, телевизордагы имансыз кешеләр дөньясы мөселман хатын-кызларын бөтенләй гарык иткән, эсселеккә дә карамыйча үзләре рульләр артына утырып, авылдашларын алып, йөзәр чакырым араны үтеп (Гафури, Миякә, Авыргазы районнарыннан) әдәп, әхлак, дин турында сөйләшүгә ныклап әзерләнеп, төнне көнгә ялгап җигелеп эшләгән ханымнар ”әйдәгез эшлик, бергә эшлик, безнең дөньяны, безнең балаларны чит-ятлар кайгыртмас” дип үзләренең максатчанлыклары, тырышлыклары, авырлыклар килсә аларга да әзер булуларын күрсәтеп уфалыларны сокландырып киттеләр. Сәламәтлек, уңышлар телик аларга, шундый була алуларына рәхмәт әйтик!

# Яхшы үрнәк күрсәтегез

Әхмәд ШАҺИН

Корбан чалу хәлле кешеләрнең вазифасыдыр. Шуңа күрә корбан чалырга теләгән кеше матди хәлен күздән кичереп, шуннан чыгып эш итәргә тиеш. Ләкин башта бер сорауга җавап бирергә кирәк. Байлык нәрсә белән үлчәнә? Бу кеше корбан чалыр өчен җитәрлек дәрәҗәдә бай, теге кеше исә алай ук бай түгел дип әйтү өчен нинди мизан кулланыла?

Мәсәлән, зәкят бирү өчен кешенең байлыгы билгеле бер күләмдә булырга тиеш. Һәм шул кеше байлыгының кырыктан бер өлешен елына бер тапкыр садака итеп бирә. Ләкин корбан чалу өчен мондый шарт куелмый. Әгәр кешедә бәйрәм көннәренең берсендә корбан чалырга җитәрлек акча (мал) булса, аңа корбан чалу важиб ителә.

Корбан чалу өчен ни дәрәҗәдә бай булу мәсьәләсе кайберәүләр уйлаганча ук катлаулы түгел. Әгәр кешенең бурычы булмаса, корбан чалуга китәчәк акча көндәлек тормышны авыр хәлгә куймаса, көндәлек ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә комачауламаса, бу кеше корбан чалырга, корбан ите белән гаиләсен һәм күршеләрен сыйларга тиеш.

Әгәр инде кешенең артык акчасы булмаса, өстәвенә ул кемнәргәдер бурычлы да булса, ул вакытта корбан чалу аның өчен мәҗбүр түгел. Инде матди тарлыкка карамастан, тегеннән-моннан акча җыеп корбан чалса, корбан нафилә, ягъни фарыз һәм важиб булмаган эш саналыр. Матди хәле бик үк шәптән булмаган кешенең корбан чалуы башкалар өчен юмартлык үрнәге күрсәтү булыр. Ягъни бу кеше хәллерәкләр дә корбан чалмаган вакытта үзенең ихласлык дәрәҗәсен ачык күрсәтер.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) Хәзрәтләре болай дигән:

- Хәлле булуына карамастан корбан чалмаган кеше безнең намазгяһыбызга (намаз укылган урынга) якын килмәсен!

Бу хәдистә икяз (кисәтү) һәм иршад (туры юлга күндерү) бар. Матди хәле әйбәт булып та, корбан чалмаган кеше халык арасында чыгып йөрергә, кешеләргә начар үрнәк күрсәтергә тиеш түгел. Хәдис бу хакта кисәтә. Иршадка килсәк, аның бу хәдистәге мәгънәсе болай аңлатыла: хәлегез җитә икән, корбан чалыгыз, намазгяһка килегез, дин кардәшләрегез белән бәйрәм шатлыгын уртаклашыгыз, үзегезне уңайсыз хәлгә куймагыз.